ГЛАВА ДЫМ-ТАМАКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
с.Дым-Тамак, ул.Новая, д.4в, 423955

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Димтамак авылы, Яна урам, 4 в йорт, 423955

Тел.:(85593) 4-52-37, факс:4-52-37, e-mail: Dtam.Utz@tatar.ru

**Постановление** **Карар**
**№ 6** **2020 ел 2 ноябрь**

Ютазы муниципаль районыДим-Тамак авыл җирлегенең Екатериновка бистәсендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә кабул ителгән Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә, К А Р А Р И Т Ә М:

1. 2020 елның 13 ноябренә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы, Дим-Тамак авыл җирлеге, Екатериновка бистәсенең, Яшел урам, 13 нче йорт каршында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

Ютазы муниципаль районы Дим-Тамак авыл җирлеге Екатериновка бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигълык яшенә җиткән, балачактан инвалид булган, I һәм II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга сез ризамы:

- Екатериновка бистәсендә вак таш җәеп юлны ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Димтамак авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенын оештыруны һәм үткәрүне йөкләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», www.yutaza.tatar.ru веб-адрес буенча Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштырырга.

5. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көненнән үз көченә керә.

"Дим-Тамак авыл җирлеге"
муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары Ф.М.Гарипов